**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 апрель № 309

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елда социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмат ресурсы турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 14 гыйнвар, 11 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елда социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмат ресурсы турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 14 гыйнвар, 11 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 12 сентябрь, 661 нче, 2014 ел, 23 декабрь, 1014 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Эшмәкәрлек проблемаларын өйрәнү анкетасы (бер тапкыр бирелә торган) республика дәүләт статистик күзәтүе формасын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

күрсәтелгән карар белән расланган № 1-бүлү (елга 1 тапкыр) «Эш хакы күләмнәре буенча хезмәткәрләр санын бүлү турында мәгълүматлар» республика дәүләт статистик күзәтүе формасын әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\309.doc